Туган туең сабый

Бала туу белән бәйле йолалар

Муниципаль мәдәни казна учреждениесе
Үзәкләштерелгән Малмыж китапханә системасы
Г. Тукай исемендәге Иске Йөрек авыл китапханәсе –
татар мәдәни үзәге

Туган туең сабый

Бала туу белән бәйле йолалар

Иске Йөрек
2017

Төзүчесе
Е. Н. Касимова

Компьютерда җыючы
Е. Н. Касимова

Чыгарылыш өчен җаваплылык
М. Т. Хасанова

Туган туең сабый: Бала туу белән бәйле йолалар / төз. Е. Н. Касимова, җаваплы ред. М. Т. Хасанова. – Малмыж : ММКУ Малмыж ҮКС, Г. Тукай исемендәге Иске Йөрек КФ, 2017.- 16 б.

Җыентыкка гасырлар тирәнлегеннән безнең көннәргәчә килеп җиткән татар халкының бала тууына багышланган йолалар тупланган. Иске Йөрек авылы тарихы нигезендә җыелган материал да урын алды.

©ММКУ Малмыж ҮКС, 2017
Т. 15 экз.

Бала туу белән бәйле йолалар

Соңгы елларда халкыбызның рухи мирасын барлауга һәм өйрәнүгә зур кызыксыну уянды. Рухи мәдәниятебезнең нигезе булган туган телне саклау, гореф – гадәтләребезне җыю һәм теркәү, халык йолалары, бәйрәмнәре, аларның матурларын, рухыбызга хуш килгәннәрен сайлап алып, халыкка кире кайтарып бирү бик кирәк эш.

Татар халкы һәм аның теле, йолалары һәм гореф – гадәтләренең төп сакчысы – авыл халкы. Авыл – шәһәрнең анасы, диләр. Авылларда сакланып калган җирле сөйләмнәр безгә халкыбызның үзенә генә хас булган кабатланмас тормыш чынбарлыгын, гасырлар тирәнлегеннән килгән борынгы атамалар, сөйләм үрнәкләрен китереп җиткергәннәр. Борынгыдан бүгенге көнгә килеп җиткән йолалар икегә бүленә: гаилә – көнкүреш һәм календарь йолалары. Гаилә йолалары исә туй, бала туу һәм кеше күмү, искә алу йолаларына бүленә. Татар халкында бала туу белән бәйле булган йолалар күп сакланмаган булса да, кайбер өлкән кешеләр баланы һәм бала тудырган хатынны “явыз рухлардан” саклау, төрле ышанулар, ырымнар белән үрелеп барган, буыннан – буынга күчеп тапшырылып килгән борынгы йолаларны әле дә хәтерлиләр.

Булачак әнигә киңәшләр

Бала тугәнга кадәр, аның әнисенә карата әйләнә – тирәдәгеләр яхшы мөнәсәбәттә булырга тиеш. Авырлы хатын – кызны үпкәләтергә, кыерсытырга ярамый, чөнки бу шарттан баланың нинди булып туасы бәйле. Йөкле хатынны рәнҗетү дә кабул ителми, аның рәнҗеше төшүе мөмкин. Авырлы хатынга күзе төшкән, нәфесе кагылган ризыкны ашату да кирәк дип санала, чөнки бу баланың зәгыйфь булып тууына китерергә мөмкин. Шулай ук авырлы хатынга кайбер эшләрне эшләүгә тыюлык булган: бигрәк тә җеп эрләп, җеп кату һәм физик авыр эшләр. Җеп эрләп, җеп катса, баланың кендеге муенына

чолганучан була диләр. Аннан соң эчү – тартудан катгый тыелырга кирәк санала. Бала көткән хатынга мәет озату, зиратка керү буенча да аерым теләкләр өстенлек итә. Үлгән кеше өстенә килеп керсә, аның баласы төшү куркынычы бар, зиратка да керергә ярамый. Әгәр дә бу шартларны үтәргә мөмкинчелек юк икән, ул очракта күкрәгенә энә, яисә кадавыч (булавка) тагып йөрергә киңәш ителә. Авырлы хатынга чәч кисү буенча да катгый тыюлык булмаса да, бу эш, сәбәбе күрсәтелмәсә дә, хупланмый. Йөкле хатынның ялгыз гына кунуы да куркыныч табыла, чөнки аңа җеннәр тәэсир итеп, баласы төшү куркынычы туа. Туачак баланың кыз яки ир бала булуын, йөкле хатынның йөзенә карап фаразлаганнар: йөзенә туп (кара кучкыл тап) төшсә – кыз, йөзе чиста булса, малай була. Туачак балага киемне дә алдан әзерләргә кирәкми, чәнки бу баланың кыска гомерле булуы мөмкин дип кисәтелә. Йөкле хатын бала табарга тиешле дип уйлаган вакыттан артык йөрсә, аңа арт итәгенә салып, атка солы ашатырга киңәш ителә.

Бала бирнәсе

Гаиләдә туган беренче балага бирнә (иң кирәкле, беренче әйберләр) әзерләнә. Бирнәгә кергән юрганны, урын – җир кирәк – яракларын, баланың әнисе ягыннан әбисе әзерли. Бәби арбасын әтисе туганнары, яисә әтисе ала. Бишек әзерләү дә бик хуплана, чөнки бишек – халык сынамышында, ярты ана дип санала. Бишекне миләш агачыннан үрү, яисә сырлап ясау хуш күрелә, чөнки миләш агачы сынмый, яхшы бөгелә һәм күп зәхмәттән саклый. Бишек ясарга кисә торган агачның күплесен кисәргә кушалар. Күплесен киссәң, балалар күп булыр, өйләр гөрләп торыр. Бишек өчен, ялгыш кына да, каен агачы ярамый, өенне кайгы басар.

Бала туу, сөенче алу

Бала туу гаиләгә зур сөенеч китерә. Бала туганны әйткән кешегә (сөенче китерү) бүләк бирелә. Бу бүләк кем әйтүенә

карап бирелә: ир – атка олырак, хатын – кызгә – сөлге, яулык ише әйберләр, баларга – тәм – том, кемнең көченнән ничек килә. Сөенче бүләген сөенчене кемгә җиткерәсең, шул бирә. Яңа туган баланы иң элек әтисенең эчке күлмәгенә төрергә кушалар, бала атасына якын булыр дип. Шифаханәдән алып кайткач та баланың чәчен алып, мунча кертәләр. Баланы югач, тфү – тфү дип, баланың гәүдәсеннән суын суырасың да, тфү – тфү диеп, мунча ташына төкерәсең өч мәртәбә. “Су күк үткен булсын, таш күк таза булсын”, дип. Бу эшләрне, үз ата – анасыннан башка, чит кеше башкарса, сәдака бирелә. Беренче чәч белән тиз күз тиючән һәм китми торган була диләр. Алган чәчне ишек өстенә куеп саклыйлар. Шушы чәчне киптереп үлчәп, шул авырлыктагы көмеш бәясен исәпләп, хәллерәк кешеләр, бала туу хөрмәтенә сәдака да бирергә мөмкин. Күз тиюдән баланы төрле ысуллар белән саклыйлар: баш түбәсенә бер чеметем тоз кую, киеменә миләш, шомырт агачларыннан кечкенә генә кисәкләр тагу, бөти ясап киертү. Кайберәүләр корым сөртергә куша, ләкин моны бик хупламыйлар, чөнки корым аша тигән күз гомергә китмәс, дигән сынамыш бар. Тырнакларны исә сакламыйлар, яндыралар. Балага кырык көн булмыйча, баланы ялгыз калдырырга ярамый, җен алыштыра ала. Әгәр дә бала янында калырга кеше булмаса, янына пычак яисә кайчы куеп китәләр. Баланың беренче тешен күргән кеше балага бүләк алып бирә. Гадәттә бу – күлмәк була. Төшкән сөт тешләрен теләсә кая ташларга ярамый, агач өйләрдә аны бүрәнә ярыгына кыстыралар, яисә кош – корт тия алмаслык җирдә саклыйлар. Ир бала туса, ата – ананың изге бурычы булып, аны сөннәтле итү тора. Бу эш хәзерге көндә шифаханәләрдә эшләнә. Кыз баланың колагын тиштерү киң таралган. Моны кыш көне, тавык йомырка салудан туктагач эшлиләр. Колак бозылучан булмасын өчен.

Бала туу хөрмәтенә мәҗлесләр

Мөселман кешесенең гомерендә өч туй була. Беренчесе – бала тугач исем кушу. Бала туганнан соң мөмкин кадәр тизрәк исем кушу кирәк. Исемне, гадәттә, мулла куша. Баланың битен ябып мендәргә салып китерәләр. Мулла баланың уң колагына да, сул колагына да өчәр тапкыр, азан әйтеп исемен кычкыра. Исем кушкан өчен муллага бүләк, яисә сәдака бирелә. Мулла чакыру мөмкинчелеге булмаганда, тиешле догаларны укып, бу эшне башкару баланың әтисенә дә рөхсәт ителә. Балага исем сайлаганда ялгышмаска, бик төптән уйлап эш итәргә, иман нурында дөньяга килгән газиз, йөрәк – җимеш балабызга чын мөселман исеме кушсак иде.

Көченә күрә, балага исем кушуны зур мәҗлес – бәби туе итеп тә уздырырга мөмкин. Ир бала туса – ике, кыз бала туса – бер корбан чалына. Мондый корбан сөннәт корбаны дип атала һәм аны үти алу бик тә күркәм гамәл санала. Терлекнең итен иң яхшысы – өч өлешкә бүлү. Берсен өйдә ашарга, икесен туганнарга, күршеләргә һәм ярлыларга өләшү. Бу итне бәби туена да пешерергә мөмкин. Гадәттә, бәби туена көндез олылар, кичкә яшьләрне чакыралар. Мәҗлескә чакырулы кунаклар бүләк белән килә. Бу бәбәй ашы китерү була, ул пешкән мич ризыгыннан һәм балага кирәк – ярактан тора. Моны мәҗлестән соң да эшләргә мөмкин. Бәбәй ашы китергән кешене чәйләп (сыйлап, кунак итеп) җибәрү гадәткә кергән. Бу йолалар хәзер дә саклана. Бу исә дини йола гына түгел, ә милли традиция дә, гаилә тантанасы, олы бәйрәм дә. Бу йоланы саклау гаиләгә бәхет, шатлык китерә, аны бозу – зур кимчелек дип саналырга тиеш.

Гаилә учагын тагын да нурландырып, дөньяга сабый туа. Ата – ана шатлыгының чиге юк. Шушы көннән башлап, ямь өстенә ямь өстәп, бу йорттан назлы бишек җыры ишетелә башлый. Кеше баласы ягымлы матур сүзгә, изге теләккә, моңлы авазга мохтаж. Халык аны гасырлар буена бала күңеленә бишек җыры аша җиткерә килгән. Беренче еллар, һичшиксез, кеше өчен иң мөһим, кабатланмый торган чор.

Бишек җырлары белән безнең киләчәгебез шәкелләнә. Балаларны шул могҗизалы җырлардан мәхрүм итмәскә иде.

Бишек җырлары

Татар халык бишек жырлары:

Әлли — бәлли итәр бу,
Йокларга китәр бу,
Бәү — бәү итеп, күз йомып,
Изрәп кенә китәр бу.
Алма кебек тәгәрәп,
Үсеп буйга житәр бу,
Абыйлары артыннан
Мәдрәсәгә китәр бу.
Мәдрәсәләрдә укыгач,
Галим булып житәр бу.

***

Әлли — бәлли итәргә
Ал бишеге бар аның,
Алдына алып йоклатырга
Үз әбкәсе бар аның.
Ал бишеге бар аның,
Гөл бишеге бар аның.
Өзгәләнеп сөяргә
Үз әнкәсе бар аның.

***

Әлли итәр бу бала,
Бәлли итәр бу бала,
Әткәсенә, әнкәсенә
Хезмәт итәр бу бала.
Үчтеки, Үчтеки,
Үсмәгәнгә кечтеки,
Илдә — Жирдә бер булыр,
Бер дип әйткән ул булыр

Татар халык бишек жыры:
Үземнең кызым син
Күземнең нуры син,
Үземнең кызым син
Күземнең нуры син.

Яз кояшым, таң йолдызым
Син чәчәкләргә тиң,
Яз кояшым, таң йолдызым
Син чәчәкләргә тиң.

Минем кызым, тәүге җырым,
Яз кояшым, таң йолдызым
Син чәчәкләргә тиң,
Син еласаң балам
Кошлар тынып кала,
Син еласаң балам
Кошлар тынып кала.

Чишмә челтерәп ага- ага сиңа җыр чыгара,
Чишмә челтерәп ага - ага сиңа җыр чыгара
Минем кызым,
Минем балам,
Чишмә челтерәп ага - ага сиңа җыр чыгара.
Кашын кыйгач кара,
Күзең йомлып бара.
Кашын кыйгач кара,
Күзең йомлып бара.

Матур төшләр күрә-күрә,
Йокла газиз балам.
Матур төшләр күрә-күрә,
Йокла газиз балам.

Минем кызым,
Минем жырым,
Матур төшләр күрә-күрә,
Йокла газиз балам.
Матур төшләр күрә-күрә,
Йокла газиз балам,
Йокла газиз балам.

Татар халык бишек жыры:
Әлли-бәлли итәргә
Ал бишеге бар аның,
Өзгәләнеп тирбәтергә
Үз әнисе бар аның.

Әлли-бәлли, бәбкәсе,
Чәй хәзерли әнкәсе,
Бал китерә әткәсе,
Бармаклар бу бәбкәсе.

Әткәсенең нисе бу?
Алтын ияр кашы бу.
Әнкәсенең нисе бу? –
Йөрәгенең мае бу.

Әтисенә ай кебек,
Әнисенә көн кебек,
Килеп киткән кешегә
Кадерлеге юк кебек.

Әтисе анын куй суяр,
Әнисе аның май туглар,
Ач балакай ашап туяр,
Елауларын ташлап куяр.

Габдулла Тукай шигыре.
Татар халык көе.
Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу,
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып житәр бу.

Йокла, углым, йом кузең,
Йом, йом кузең, йолдызым,
Кичтән йокың кала да,
Еглап утә көндезең.

Әлли-бәлли көйләрем,
Хикәятләр сөйләрем,
Сиңа теләк теләрем,
Бәхетле бул, диярем.

Гыйззәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син,
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, синсен, син!

Кызыма. Муса Жәлил шигыре. Жәудәт Фәйзи көе.
Шаян кызым син минем,
Таң йолдызым син минем,
Йөрәгемдә кабынган
Шатлык жырым син минем.

Синен гомрен жыр булып
Яңрар бәхет илендә,
Йолдыз булып янарсың
Син туган ил күгендә.

Таңнан торып, бакчада
Син уйнадын көнозын.

Аргансындыр, кил, кызым,
Йокла инде, йолдызым!

Әлли — бәлли, бәлли — бәү!
Әлли — бәлли, бәлли — бәү!

Кулланылган әдәбият

1. Баязитова, Ф. С. Гомернең өч туе / Ф. С. Баязитова. – Казан : Тат. кит. нәшр., 1992. - 295 б.

2. Бишек җырлары: җырлар җыентыгы. – Казан : Тат. кит. нәшр., 2000. – 104 б. : нот. б-н.

3. Саматов, Г. Шәригать / Г. Саматов. – Казан : Идел – Пресс нәшр., 2006. – 446 б.

4. Иске Йөрек авылы халкы истәлекләреннән.

Татарские народные традиции и обряды по случаю рождения ребенка / сост. Е. Н. Касимова, отв. за выпуск М. Т. Хасанова. – Малмыж : МКУК Малмыжская ЦБС, Ст. Ирюкская СБФ – центр татарской культуры им. Г. Тукая, 2017. - 16 с.

В сборник включены татарские народные традиции и обряды по случаю рождения ребенка. Материал собран на основе семейно – обрядовых традиций жителей села Старый Ирюк Малмыжского района Кировской области.

Муниципальное казенное учреждение культуры
Малмыжская централизованная библиотечная система
Староирюкская сельская библиотека – филиал № 29
Центр татарской культуры им. Г. Тукая
Адрес:
612941, Кировская область, Малмыжский район,
село Старый Ирюк, ул. Садовая, дом 2-а;
Дом культуры, 2-й этаж
casimova.lena2015@yandex.ru